**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№512**
**04.02.2019**

Яр Чаллы шәһәре территориясендә «Торак-2019» профилактика операциясе үткәрү турында

Янгын куркынычсызлыгы буенча беренчел чараларны тәэмин итү максатында, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсе нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. 2019 елның 5 февраленнән 30 декабренә кадәрге чорда Яр Чаллы шәһәре территориясендә «Торак-2019» профилактика операциясе үткәрергә.

2. Тәкъдим итәргә:

1) идарәче оешмаларга, торак милекчеләре ширкәтләренә, торак кооперативларына һәм башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларына «Торак-2019» профилактика операциясен үткәрү чорында түбәндәгеләрне оештыруны:

- күп фатирлы йортларның торак милекчеләренең янгынга каршы чаралар оештыру мәсьәләсе буенча гомуми җыелышын үткәрү;
- гражданнарны яшәү урыны буенча янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү, шул исәптән янгынга каршы чаралар үткәрү турында мәгълүмат әзерләү һәм тарату;
- халык арасында янгынга каршы тематикага агитация һәм пропаганда материаллары әзерләү һәм тарату;

2) Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ баш идарәсе күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эшләр идарәсенең Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлегенә Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсе, Башкарма комитетның районнар хакимиятләре белән берлектә:

- профилактика төркемнәренә социаль яраклашмаган гражданнарның, аерым алганда, наркотик чаралар яки спиртлы эчемлекләр артык күп

кулланучы затларның, күп балалы уңышсыз гаиләләрнең, өлкән яшьтәге гражданнарның, авыр тормыш шартларына юлыккан затларның яшәү урыннарын тикшерүне дәвам итәргә һәм янгын куркынычсызлыгы таләпләрен бозу очракларын бетерү буенча чаралар күрергә;

- «Торак-2019» профилактика операциясе үткәрү буенча янынга каршы чараларның план-графигын эшләргә;

- «Торак-2019» профилактика операциясен үткәрү өчен ирекле янгын сүндерү командалары һәм ирекле янгын сүндерү дружиналары әгъзаларын җәлеп итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин